**Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының "арендалана торган мөлкәтне милеккә алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты" 26.07.2021 № 471 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:
1. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 26.07.2021 № 471 карары белән расланган арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә:
1) 2 бүлекнең 2.9.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.9.2. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алына торган арендалана торган мөлкәткә түләү бер мәртәбә яисә айлык яисә квартал саен бертигез өлешләрдә түләүләр ярдәмендә кичектереп түләнә».

2) 2 бүлекнең 2.9.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.9.3. Мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда аны түләүне кичектереп түләү срогы тиешенчә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый акты, Россия Федерациясе субъекты законы, муниципаль хокукый акт белән билгеләнә, ләкин күчемсез мөлкәт өчен биш елдан да кимрәк һәм күчемле мөлкәт өчен өч елдан да кимрәк булмаска тиеш».

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**